**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 27 ноябрь № 901

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2015 ел, 26 февраль, 120 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 апрель, 233 нче; 2015 ел, 11 июнь, 441 нче; 2015 ел, 15 июль, 513 нче; 2015 ел, 14 август, 590 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган 2015 елга агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү өчен «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законында каралган финанслау күләмнәрен бүлүдә:

1 нче пунктта «1 000 000,0» саннарын «1 494 151,0» саннарына алмаштырырга;

2 нче пунктта «50 000,0» саннарын «45 602,8» саннарына алмаштырырга;

3 нче пунктны төшереп калдырырга;

6 нчы пунктта «290 000,0» саннарын «239 678,7» саннарына алмаштырырга;

7 нче пунктта «160 000,0» саннарын «154 230,0» саннарына алмаштырырга;

8 нче пунктта «10 000,0» саннарын «15 770,0» саннарына алмаштырырга;

9 нчы пунктта «300 000,0» саннарын «257 413,2» саннарына алмаштырырга;

11 нче пунктта «25 000,0» саннарын «30 000,0» саннарына алмаштырырга;

12 нче пунктта «533 555,6» саннарын «569 293,6» саннарына алмаштырырга;

13 нче пунктта «59 800,0» саннарын – «27 473,0» саннарына, «44 800,0» саннарын – «25 162,0» саннарына, «15 000,0» саннарын «2 311,0» саннарына алмаштырырга;

14 нче пунктта «275 000,0» саннарын – «319 993,6» саннарына, «80 000,0» саннарын – «88 601,6» саннарына, «190 000,0» саннарын «226 392,0» саннарына алмаштырырга;

16 нчы пунктта «155 000,0» саннарын – «160 006,4» саннарына, «105 000,0» саннарын «110 006,4» саннарына алмаштырырга;

17 нче пунктта «2 240 894,0» саннарын «1 835 680,0» саннарына алмаштырырга;

18 нче пунктта «60 000,0» саннарын «92 900,0» саннарына алмаштырырга;

24 нче пунктта «45 000,0» саннарын «63 000,0» саннарына алмаштырырга;

28 нче пунктта «100 000,0» саннарын «85 000,0» саннарына алмаштырырга;

30 нче пунктта «13 597,299» саннарын «13 597,3» саннарына алмаштырырга;

32 нче пунктта «50 000,0» саннарын «37 327,0» саннарына алмаштырырга;

«Барлыгы» юлында «6 998 652,899» саннарын «7 066 922,6» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә үсемлекчелек өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктта «милкендә яки аренда шартларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2015 елгы уңыш ашлыгын Төбәк азык-төлек фондына һәм социаль икмәк җитештерү өчен фонд онын сатучы он тарту предприятиеләренә кайтартуны стимуллаштыру.»;

7 – 8 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә 966 350,8 мең сум күләмендә субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча финанслау лимитларын бүлү (кәбестә, бәрәңге һәм яшелчә культуралары биләгән чәчүлек мәйданнарын киңәйтүне саклау һәм стимуллаштыруга, ябык грунтта яшелчә җитештерүне, куак булмаган җиләк-җимеш үсентеләренең югары технологияле чәчүлек мәйданнарын киңәйтү һәм җитештерүне стимуллаштыруга, авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләренә фитосанитария мониторингын үткәрүгә, сапропель минераль-органик ашламалар кертү чыгымнарының бер өлешен каплауга, 2015 елгы уңыш ашлыгын Төбәк азык-төлек фондына һәм социаль икмәк җитештерү өчен фонд онын сатучы он тарту предприятиеләренә кайтартуны стимуллаштыруга субсидияләрдән тыш) түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

366 350,8 мең сум күләмендә – 2014 ел өчен авыл хуҗалыгы культуралары уңышын җыю турында рәсми статистика хисабы аның нигезендә төзелгән мәгълүматка (алга таба – уңыш җыю турында мәгълүмат) таянып, бу Тәртипкә теркәлгән кушымта нигезендә авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләре мәйданыннан чыгып;

600 000,0 мең сум күләмендә – 2015 ел өчен чәчүлек мәйданы яктыртылган рәсми статистика хисабы аның нигезендә төзелгән мәгълүматка (алга таба – чәчүлек

мәйданнары турында мәгълүмат) таянып, бу Тәртипкә теркәлгән кушымта нигезендә авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләре мәйданыннан чыгып.

8. 966 350,8 мең сум күләмендәге субсидияләр авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә түбәндәге тәртиптә бирелә:

а) барлык суммадан 366 350,8 мең сум күләмендәге авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә субсидия түбәндәге формула буенча билгеләнә торган күләмдә чәчүлек мәйданының 1 гектарына 183,48 сум исәбеннән чыгып бирелә:

W = 183,48 x Кб x S x 0,8 x 0,8 x 0,5,

монда:

W – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә бирелергә тиешле субсидия күләме;

S – уңыш җыю турында мәгълүмат нигезендә билгеләнә торган 2014 ел өчен чәчүлек мәйданы (гектарларда);

Кб – туфракларның бәяләү күрсәткечләреннән чыгып, Министрлык тарафыннан туфраклар бонитетына раслана торган төзәтү коэффициенты (икътисадый бәяләү баллы);

0,8 – 2014 елда чәчү өчен әлеге максатларга каралган, РСт категориясенә кергән орлыкларның (товар продукциясен җитештерү өчен репродукцион орлыкларның) 15 процентыннан күбрәген кулланган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияне исәпләү өчен кулланыла торган төзәтү коэффициенты;

0,8 – 2014 елда күпьеллык үләннәр структурасында дүрт елдан артыграк кулланыла торган картайган чәчүлекләре 20 процентtан күбрәк булган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияне исәпләү өчен кулланыла торган төзәтү коэффициенты;

0,5 – бишьеллык цикл буенча авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрнең агрохимик тикшерүе булмаган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияне исәпләү өчен кулланыла торган төзәтү коэффициенты;

б) барлык суммадан 600 000,0 мең сум күләмендәге авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә субсидия түбәндәге формула буенча билгеләнә торган күләмдә чәчүлек мәйданының 1 гектарына 205,99 сум исәбеннән чыгып бирелә:

W= 205,99 x S,

монда:

W – авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә бирелергә тиешле субсидия күләме;

S – чәчүлек мәйданнары турында мәгълүмат нигезендә 2015 ел өчен чәчүлек мәйданы (гектарларда).

Яңадан төзелгән авыл хуҗалыгы оешмаларына, шулай ук 2014 ел белән чагыштырганда 2015 елда чәчүлек мәйданнарын арттырган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр, чәчүлек мәйданнары турында мәгълүмат нигезендә, чәчүлек мәйданыннан чыгып бирелә.»;

түбәндәге эчтәлекле $13^2$ нче пункт өстәргә:

«$13^2$. Министрлык боерыгы буенча фонд онын социаль сортлы икмәкләр җитештерүгә җибәрүче Татарстан Республикасының он тарту предприятеләренә һәм Татарстан Республикасы Төбәк азык-төлек фондына 2015 елгы уңышның 3, 4

класслы азык-төлек бодаен саткан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр:

3 класслы бодайның 1 тоннасы өчен 2000 сум исәбеннән;

4 класслы бодайның 1 тоннасы өчен 1500 сум исәбеннән.»;

14 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре түбәндәге субсидияләрне алу өчен Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) түбәндәгеләрне кертәләр:

а) әлеге Тәртипнең 8 нче пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән субсидияне алу өчен, түбәндәге документларны:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза;

2014 ел өчен уңыш җыю турында мәгълүмат, яңадан төзелгән авыл хуҗалыгы оешмалары – чәчүлек мәйданнары турында мәгълүмат;

«Россельхозцентр» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы тарафыннан расланган РСт категориясендәге орлыкларны 2014 елда чәчү өчен куллану турында мәгълүмат, яңа төзелгән авыл хуҗалыгы оешмаларыннан тыш;

2010 – 2014 еллар өчен чәчү йомгаклары һәм уңыш җыю турында хисаплар нигезендә төзелгән 2014 елда күпьеллык картайган үләннәр чәчүлекләре булу турында мәгълүмат, яңадан төзелгән авыл хуҗалыгы оешмаларыннан тыш;

2015 елның 1 гыйнвары хәленә карата, яңадан төзелгән авыл хуҗалыгы оешмалары – «Татар» агрохимия хезмәте үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе яисә «Әлмәт» агрохимия хезмәте станциясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан расланган субсидия бирү турында гаризаны теркәү көненә карата агрохимик тикшерү булу турында мәгълүмат;

бирелергә тиешле субсидияләр турында Министрлык раслаган форма буенча белешмә-исәп-хисап;

б) әлеге Тәртипнең 8 нче пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән субсидияне алу өчен, түбәндәге документларны:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза;

чәчүлек мәйданнары турында мәгълүмат;

бирелергә тиешле субсидияләр турында Министрлык раслаган форма буенча белешмә-исәп-хисап.»;

түбәндәге эчтәлекле $19^2$ нче пункт өстәргә:

«$19^2$. Әлеге Тәртипнең $13^2$ нче пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Идарәгә түбәндәге документларны кертәләр:

үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза;

ашлык кайтарту турында шартнамә;

исәп-фактура һәм (яки) йөкнамә;

бирелергә тиешле субсидия турында Министрлык раслаган форма буенча белешмә-исәп-хисап.»;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә үсемлекчелек өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә үсемлекчелек өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә субсидияләр бирүгә финанслау лимитларын Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

| Т/с | Муниципаль район, дәүләт ярдәме юнәлеше исеме | Финанслау лимиты, барлыгы, мең сум | Шул исәптән 1 гектар чәчүлек мәйданына түбәндәгеләр исәбеннән чыгып | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 183,48 сум, туфраклар бонитетына төзәтү коэффициентын исәпкә алып | 205,99 сум |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Әгерҗе | 22625,6 | 10487,6 | 12138,0 |
| 2 | Азнакай | 34468,6 | 13458,6 | 21010,0 |
| 3 | Аксубай | 18334,6 | 3295,6 | 15039,0 |
| 4 | Актаныш | 33513,2 | 14631,2 | 18882,0 |
| 5 | Алексеевск | 28509,3 | 9560,3 | 18949,0 |
| 6 | Әлки | 33516,6 | 15448,6 | 18068,0 |
| 7 | Әлмәт | 23126,4 | 7788,4 | 15338,0 |
| 8 | Апас | 23974,5 | 10128,5 | 13846,0 |
| 9 | Арча | 36138,7 | 11471,7 | 24667,0 |
| 10 | Әтнә | 18407,6 | 9155,6 | 9252,0 |
| 11 | Баулы | 18739,2 | 8590,2 | 10149,0 |
| 12 | Балтач | 27312,1 | 13301,1 | 14011,0 |
| 13 | Бөгелмә | 19570,5 | 6946,5 | 12624,0 |
| 14 | Буа | 33336,5 | 13333,5 | 20003,0 |
| 15 | Югары Ослан | 14264,7 | 7189,7 | 7075,0 |
| 16 | Биектау | 24667,8 | 11627,8 | 13040,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 17 | Чүпрәле | 22447,7 | 8554,7 | 13893,0 |
| 18 | Алабуга | 19639,7 | 8461,7 | 11178,0 |
| 19 | Зәй | 24918,3 | 10667,3 | 14251,0 |
| 20 | Зеленодольск | 14030,7 | 5993,7 | 8037,0 |
| 21 | Кайбыч | 20614,8 | 9259,8 | 11355,0 |
| 22 | Кама Тамагы | 20884,8 | 10157,8 | 10727,0 |
| 23 | Кукмара | 22283,2 | 7202,2 | 15081,0 |
| 24 | Лаеш | 15669,8 | 5375,8 | 10294,0 |
| 25 | Лениногорск | 17396,6 | 4879,6 | 12517,0 |
| 26 | Мамадыш | 26666,6 | 9544,6 | 17122,0 |
| 27 | Менделеевск | 10342,0 | 4419,0 | 5923,0 |
| 28 | Минзәлә | 19612,3 | 2967,3 | 16645,0 |
| 29 | Мөслим | 18562,9 | 3129,9 | 15433,0 |
| 30 | Түбән Кама | 15220,8 | 5345,8 | 9875,0 |
| 31 | Яңа Чишмә | 25328,4 | 8525,4 | 16803,0 |
| 32 | Нурлат | 21010,7 | 4428,7 | 16582,0 |
| 33 | Питрәч | 22130,6 | 9088,6 | 13042,0 |
| 34 | Балык Бистәсе | 30456,4 | 14011,4 | 16445,0 |
| 35 | Саба | 20845,5 | 10584,5 | 10261,0 |
| 36 | Сарман | 29737,5 | 12052,5 | 17685,0 |
| 37 | Спас | 22530,2 | 8821,2 | 13709,0 |
| 38 | Тәтеш | 24725,4 | 9995,4 | 14730,0 |
| 39 | Тукай | 26371,6 | 11324,6 | 15047,0 |
| 40 | Теләче | 13011,2 | 3875,2 | 9136,0 |
| 41 | Чирмешән | 12550,0 | 0,0 | 12550,0 |
| 42 | Чистай | 27186,1 | 7271,1 | 19915,0 |
| 43 | Ютазы | 11671,1 | 3998,1 | 7673,0 |
| Муниципаль районнар буенча барлыгы | | 966 350,8 | 366 350,8 | 600 000,0 |
| Кәбестә, бәрәңге һәм яшелчә культуралары биләгән чәчүлек мәйданнарын киңәйтүне саклау һәм стимуллаштыру | | 150 000,0 | | |
| Ябык грунтта яшелчә җитештерүне стимуллаштыру | | 35 000,0 | | |
| Куак булмаган җиләк-җимеш үсентеләренең югары технологияле чәчүлек мәйданнарын киңәйтү һәм җитештерүне стимуллаштыру | | 2 800,0 | | |
| Авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләренә фитосанитария мониторингын үткәрү | | 30 000,0 | | |
| Сапропель минераль-органик ашламалар кертү чыгымнарының бер өлешен каплау | | 10 000,0 | | |
| 2015 елгы уңыш ашлыгын Төбәк | | 300 000,0 | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| азык-төлек фондына һәм социаль икмәк җитештерү өчен фонд онын сатучы он тарту предприятиеләренә кайтартуны стимуллаштыру | | | |
| Барлыгы | 1 494 150,8»; | | |

әлеге карар белән расланган 2015 елга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең сатып алынган оригиналь һәм затлы орлыклар буенча чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

7 нче пунктта «31 000,0» саннарын «26 602,8» саннарына алмаштырырга;

бу Тәртипкә теркәлгән кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 елга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең сатып алынган оригиналь һәм затлы орлыклар буенча чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

2015 елга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең
сатып алынган оригиналь һәм затлы орлыклар буенча чыгымнарының
бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә финанслау лимитларын
Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

| Т/с | Муниципаль районнар, дәүләт ярдәме юнәлешләре исеме | Субсидияләр лимиты, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе | 474,1 |
| 2 | Азнакай | 927,2 |
| 3 | Аксубай | 679,9 |
| 4 | Актаныш | 844,2 |
| 5 | Алексеевск | 865,4 |
| 6 | Әлки | 856,8 |
| 7 | Әлмәт | 732,4 |
| 8 | Апас | 628,3 |
| 9 | Арча | 1044,6 |
| 10 | Әтнә | 406,9 |
| 11 | Баулы | 464,8 |
| 12 | Балтач | 628,3 |
| 13 | Бөгелмә | 581,4 |
| 14 | Буа | 872,4 |
| 15 | Югары Ослан | 323,0 |
| 16 | Биектау | 582,9 |

| | | |
|---|---|---|
| 17 | Чүпрәле | 581,4 |
| 18 | Алабуга | 456,9 |
| 19 | Зәй | 664,3 |
| 20 | Зеленодольск | 362,3 |
| 21 | Кайбыч | 482,0 |
| 22 | Кама Тамагы | 441,3 |
| 23 | Кукмара | 679,9 |
| 24 | Лаеш | 460,0 |
| 25 | Лениногорск | 553,2 |
| 26 | Мамадыш | 687,8 |
| 27 | Менделеевск | 203,4 |
| 28 | Минзәлә | 725,3 |
| 29 | Мөслим | 738,6 |
| 30 | Түбән Кама | 456,2 |
| 31 | Яңа Чишмә | 758,2 |
| 32 | Нурлат | 751,9 |
| 33 | Питрәч | 586,0 |
| 34 | Балык Бистәсе | 701,8 |
| 35 | Саба | 477,3 |
| 36 | Сарман | 787,9 |
| 37 | Спас | 654,9 |
| 38 | Тәтеш | 619,7 |
| 39 | Тукай | 713,6 |
| 40 | Теләче | 402,2 |
| 41 | Чирмешән | 570,4 |
| 42 | Чистай | 852,9 |
| 43 | Ютазы | 320,8 |
| Муниципаль районнар буенча барлыгы | | 26 602,8 |
| Сатып алынган оригиналь һәм затлы рапс орлыклары буенча чыгымнарының бер өлешен каплауга | | 2 000,0 |
| Сатып алынган оригиналь һәм затлы күпьеллык үләннәр орлыклары буенча чыгымнарының бер өлешен каплауга | | 3 000,0 |
| Сортларга экологик зона сынавы | | 2 000,0 |
| Орлыкчылык хуҗалыкларын стимуллаштыру | | 10 000,0 |
| Туфраклы сортлы тикшерү үткәрү | | 2 000,0 |
| | Барлыгы | 45 602,8»; |

әлеге карар белән расланган 2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә территорияләрне аеруча куркыныч корткычларга каршы эшкәртүгә бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибе үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда әче туфракларга известь кертү чараларын финанслау тәртибенә кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 елда әче туфракларга известь кертү чараларын финанслау тәртибенә кушымта

2015 елда әче туфракларга известь кертү чараларын финанслау лимитларын Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

(мең сум)

| Т/с | Муниципаль район исеме | Финанслау лимиты | Шул исәптән шикәр чөгендере чәчүгә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Әгерҗе | 12 186,7 | - |
| 2 | Азнакай | 3 700,4 | - |
| 3 | Аксубай | 3 974,1 | 994,0 |
| 4 | Актаныш | 8 495,3 | - |
| 5 | Алексеевск | 5 359,3 | - |
| 6 | Әлки | 12 417,6 | - |
| 7 | Әлмәт | 6 435,6 | - |
| 8 | Апас | 6 356,0 | 1 589,0 |
| 9 | Арча | 6 931,1 | - |
| 10 | Әтнә | 8 994,8 | - |
| 11 | Баулы | 706,5 | - |
| 12 | Балтач | 7 464,5 | - |
| 13 | Бөгелмә | 514,4 | 129,0 |
| 14 | Буа | 10 926,1 | 2 732,0 |
| 15 | Югары Ослан | 2 299,4 | - |
| 16 | Биектау | 3 640,7 | - |
| 17 | Чүпрәле | 8 825,7 | 2 206,0 |
| 18 | Алабуга | 8 327,2 | - |
| 19 | Зәй | 6 716,3 | 1 679,0 |
| 20 | Зеленодольск | 2 411,9 | - |
| 21 | Кайбыч | 6 803,8 | 1 701,0 |
| 22 | Кама Тамагы | 1 973,1 | - |
| 23 | Кукмара | 3 136,4 | - |
| 24 | Лаеш | 6 306,7 | - |
| 25 | Лениногорск | 2 278,5 | 570,0 |
| 26 | Мамадыш | 6 136,5 | - |
| 27 | Менделеевск | 536,3 | - |
| 28 | Минзәлә | 4 977,7 | - |
| 29 | Мөслим | 2 296,3 | - |
| 30 | Түбән Кама | 4 754,1 | 1 189,0 |
| 31 | Яңа Чишмә | 4 122,2 | - |
| 32 | Нурлат | 6 052,4 | 1 513,0 |
| 33 | Питрәч | 3 641,5 | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 34 | Балык Бистәсе | 9 464,4 | - |
| 35 | Саба | 10 229,6 | - |
| 36 | Сарман | 11 152,0 | 2 788,0 |
| 37 | Спас | 2 099,4 | - |
| 38 | Тәтеш | 5 940,2 | 1 485,0 |
| 39 | Тукай | 12 367,3 | 3 092,0 |
| 40 | Теләче | 1 988,1 | - |
| 41 | Чирмешән | - | - |
| 42 | Чистай | 6 235,1 | 1 559,0 |
| 43 | Ютазы | 503,5 | - |
| | Барлыгы | 239 678,7 | 23 226,0»; |

әлеге карар белән расланган 2015 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«сөтле токымнан булган нәселле мөгезле эре терлек сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү;

дөяләр сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү.»;

17 нче пунктның икенче абзацында «мөгезле эре терлек» сүзләреннән соң «, физик затларның керемнәренә салымны исәпкә алып» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $24^3$ һәм $24^4$ нче пунктлар өстәргә:

«$24^3$. 2015 ел өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә сөтле токымнан булган нәселле мөгезле эре терлек сатып алу чыгымнарын каплауга субсидияләр бер килограмм тере авырлык өчен 84,0 сум исәбеннән чыгып бирелә.

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә сөтле токымнан булган нәселле мөгезле эре терлек сатып алу чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

2015 елда дәүләт нәсел регистрында теркәлү турындагы таныклыгы булган нәсел заводларыннан һәм нәсел репродукторларыннан, шулай ук импорт буенча сөтле токымнан булган нәселле мөгезле эре терлек сатып алу;

күп баш авыл хуҗалыгы хайваннары булу.

Субсидия алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Идарәгә түбәндәге документларны кертә:

рәсми статистика хисабы өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыру һәм норматив-хокукый җайга салу вазыйфаларын башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган форма буенча фермада терлек һәм кош-корт хәрәкәте турында хуҗалык эчендәге хисап күчермәсен;

2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең сөтле токымнан булган нәселле мөгезле эре терлек сатып алуын раслаучы банк – алучы таныклаган түләү йөкләмәсен, шартнамә, исәп-фактура, йөкнамә яки гурт ведомосте күчермәләрен;

бирелергә тиешле субсидия турында Министрлык расланган форма буенча белешмә-исәп-хисап.

$24^4$. 2013 – 2015 елларда авыл хуҗалыгы товар җитешетрүчеләренә нәселле дөяләр сатып алу чыгымнарын каплауга субсидияләр бер баш дөя өчен 44500,0 сум

исәбеннән чыгып бирелә.

Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә нәселле дөяләр сатып алу чыгымнарын каплауга субсидияләр бирү шартлары булып түбәндәгеләр тора:

2013 – 2015 елларда дәүләт нәсел регистрында теркәлү турындагы таныклыгы булган нәсел заводларыннан һәм нәсел репродукторларыннан, шулай ук импорт буенча сөтле токымнан булган нәселле дөяләр сатып алу;

күп баш нәселле дөяләр булу.

Субсидия алу өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Идарәгә түбәндәге документларны кертә:

рәсми статистика хисабы өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыру һәм норматив-хокукый җайга салу вазыйфаларын башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган форма буенча фермада терлек һәм кош-корт хәрәкәте турында хуҗалык эчендәге хисап күчермәсен;

2013 – 2015 елларда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең нәселле дөяләр сатып алуын раслаучы банк – алучы таныклаган түләү йөкләмәсен, шартнамә, исәп-фактура, йөкнамә яки көтүнең җыелма исемлеге күчермәләрен;

бирелергә тиешле субсидия турында Министрлык расланган форма буенча белешмә-исәп-хисап.»;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада:

2 нче пунктта «5 335,0» саннарын «3838,5» саннарына алмаштырырга;

5 нче пунктта «58 483,0» саннарын «59 790,0» саннарына алмаштырырга;

7 нче пунктта «12 000,0» саннарын «3 647,0» саннарына алмаштырырга;

15 нче пунктта «12 500,0» саннарын «7 780,5» саннарына алмаштырырга;

19 нчы пунктта «16 500,0» саннарын «21 500,0» саннарына алмаштырырга;

таблицага түбәндәге эчтәлекле 22 һәм 23 нче пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «22 | Сөтле токымнан булган нәселле мөгезле эре терлек сатып алу чыгымнарын каплауга субсидияләр | 40 000,0 |
| 23 | Дөяләр сатып алу чыгымнарын каплауга субсидияләр | 4 000,0»; |

«Барлыгы» юлында «533 555,6» саннарын «569 293,6» саннарына алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 елда нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта

2015 елда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең нәсел үрчеткеч авыл хуҗалыгы хайваннарын сатып алу чыгымнарын каплауга финанслау лимитларын Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

| Т/с | Муниципаль район исеме | Субсидияләр лимиты, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе | 1 154,0 |
| 2 | Азнакай | 3 637,0 |
| 3 | Аксубай | 1 602,0 |
| 4 | Актаныш | 1 188,0 |
| 5 | Алексеевск | 1 582,0 |
| 6 | Әлки | 15,0 |
| 7 | Әлмәт | 2 964,0 |
| 8 | Апас | 873,0 |
| 9 | Арча | 7 750,0 |
| 10 | Әтнә | 706,0 |
| 11 | Баулы | 174,0 |
| 12 | Балтач | 2 011,0 |
| 13 | Бөгелмә | 27,0 |
| 14 | Буа | 256,0 |
| 15 | Югары Ослан | 121,0 |
| 16 | Биектау | 4 563,0 |
| 17 | Чүпрәле | 605,0 |
| 18 | Алабуга | 86,0 |
| 19 | Зәй | 1 842,0 |
| 20 | Зеленодольск | 4 300,0 |
| 21 | Кайбыч | 161,0 |
| 22 | Кама Тамагы | 681,0 |
| 23 | Кукмара | 1 422,0 |
| 24 | Лаеш | 1 080,0 |
| 25 | Лениногорск | 2 283,0 |
| 26 | Мамадыш | 1 134,0 |
| 27 | Менделеевск | 344,0 |
| 28 | Минзәлә | 56,0 |
| 29 | Мөслим | 20,0 |
| 30 | Түбән Кама | 956,0 |
| 31 | Яңа Чишмә | 134,0 |
| 32 | Нурлат | 375,0 |
| 33 | Питрәч | 1 328,0 |
| 34 | Балык Бистәсе | 333,0 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 35 | Саба | 7 650,0 |
| 36 | Сарман | 1 400,0 |
| 37 | Тәтеш | 1 195,0 |
| 38 | Тукай | 175,0 |
| 39 | Теләче | 2 054,0 |
| 40 | Чирмешән | 9,0 |
| 41 | Чистай | 777,0 |
| 42 | Ютазы | 767,0 |
| Барлыгы | | 59 790,0»; |

әлеге карар белән расланган 2015 елда инвестиция кредитлары (заемнар) буенча процент ставкасын түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

3 нче пунктта «агросәнәгать комплексына караган теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге оешмаларга» сүзләрен «, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмаларга һәм индивидуаль эшкуарларга» сүзләренә алмаштырырга;

4 нче пунктта:

«а» пунктчасында:

икенче һәм өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары тарафыннан түбәндәгечә төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2004 елның 1 гыйнварыннан 2012 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне дә кертеп) 2 елдан алып 8 елга кадәр вакытка (итле һәм сөтле терлекчелеккә булышлык күрсәтүгә алынган кредитлардан (заемнардан) тыш) – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә җиһазлар, махсуслаштырылган транспорт, махсус техника сатып алуга, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газомотор ягулыгына күчерү һәм нәсел продукциясен (материалын) күчерү өчен җайланма сатып алуга, шулай ук күпьеллык үсентеләр һәм виноградлар утыртуга, күпьеллык үсентеләр өчен чыбыкча ялгау комплексларын төзүгә һәм төзекләндерүгә, терлекчелек комплексларын (фермаларын), терлекчелек һәм азык әзерләү объектларын, бәрәңге, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, җимеш-яшелчә продукциясен ябык грунтта җитештерү буенча теплица комплексларын, җитен һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, терлек чалу биналарын, авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм сөтне кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү пунктларын, сөт һәм ит продукциясен суытып эшкәртү һәм саклауны кертеп, төзү, төзекләндерү һәм модернизацияләүгә,

югары протеинлы авыл хуҗалыгы культураларын (кытай борчагы, бодай, арыш, кукуруз, рапс, нут һәм мисыр тарысы) тирән эшкәртү объектларын төзүгә;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) тарафыннан итле һәм сөтле терлекчелеккә булышлык күрсәтүгә алынган кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча 2008 елның 1 гыйнварыннан 2012 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне дә кертеп) 10 елдан алып 15 елга кадәр вакытка төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл хуҗалыгы техникасы сатып алуга;»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан түбәндәгечә төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:»;

егерме икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары тарафыннан 2004 елның 1 гыйнварыннан 2012 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне дә кертеп) 15 елга кадәр вакытка төзелгән, итле һәм сөтле терлекчелекне үстерүгә алынган кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә җиһазлар, махсуслаштырылган транспорт, махсус техника сатып алуга, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газомотор ягулыгына күчерү һәм нәсел продукциясен (материалын) күчерү өчен җайланма сатып алуга, шулай ук күпьеллык терлекчелек комплексларын (фермаларын), терлекчелек һәм азык әзерләү объектларын, терлек чалу биналарын, авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм сөтне кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү пунктларын, сөт һәм ит продукциясен суытып эшкәртү һәм саклауны кертеп, төзү, төзекләндерү һәм модернизацияләүгә;»;

«б» пунктчасында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2 елдан алып 8 елга кадәр вакытка:»;

тугызынчы – унберенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар (итле һәм (яки) сөтле терлекчелек белән шөгыльләнүче оешмалардан тыш) тарафыннан 2 елдан алып 8 елга кадәр вакытка – терлекчелек комплексларын

(фермаларын), объектларын, терлек чалу биналарын, авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм сөтне кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү пунктларын, аертылмаган сөт продукциясен, сыр һәм атланмай җитештерү предприятиеләрен, эремчек суын эшкәртү һәм киптерү цехларын һәм участокларын төзү, төзекләндерү һәм модернизацияләүгә, катнаш мал азыгы предприятиеләрен һәм цехларын төзү һәм төзекләндерүгә, нәсел продукциясен сатып алуга, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә терлекчелек ярдәмче тармагын үстерү максатларына;

итле терлекчелек белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 15 елга кадәр вакытка – итле токымнан булган мөгезле эре терлекнең нәсел продукциясен (материалын) сатып алуга, итле терлекчелек комплексларын (фермаларын), объектларын, терлек чалу биналарын, кабул итү, беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртү пунктларын төзү, төзекләндерү һәм модернизацияләүгә, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә итле терлекчелекне үстерү максатларына;

сөтле терлекчелек белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 15 елга кадәр вакытка – терлекчелек комплексларын (фермаларын), объектларын, сөтне кабул итү һәм беренчел эшкәртү пунктларын (сөт продукциясен суытып эшкәртүне һәм саклауны кертеп), аертылмаган сөт продукциясен, сыр һәм атланмай җитештерү предприятиеләрен, эремчек суын эшкәртү һәм киптерү цехларын һәм участокларын төзү, төзекләндерү һәм модернизацияләүгә; катнаш мал азыгы предприятиеләрен һәм цехларын төзү һәм төзекләндерүгә, нәсел продукциясен сатып алуга, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә терлекчелек ярдәмче тармагын үстерү максатларына;»;

«в» пунктчасында «агросәнәгать комплексына караган теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге оешмалар» сүзләрен «һәм авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле «в$^1$» пунктчасын өстәргә:

«в$^1$) 2015 елның 1 гыйнварыннан төзелгән инвестицион кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2 елдан алып 8 елга кадәр вакытка – үсемлекчелек ярдәмче тармагында селекция-орлыкчылык үзәкләрен төзү һәм төзекләндерүгә, шулай ук

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә үсемлекчелек ярдәмче тармагын үстерү максатларына;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 15 елга кадәр вакытка – терлекчелек ярдәмче тармагында селекция-генетика үзәкләрен төзү һәм төзекләндерүгә, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә терлекчелек ярдәмче тармагын үстерү максатларына;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, агросәнәгать комплексына караган теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге оешмалар тарафыннан 2 елдан алып 8 елга кадәр вакытка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә күпләп сату-бүлү үзәкләрен үстерүгә;»;

«г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) әлеге пунктның «а» – «в$^1$» пунктчалары белән каралган кредитларны (заемнарны) яңадан финанслауга алынган кредитлар (заемнар) буенча, кредитлардан (заемнардан) файдалануның гомуми вакыты әлеге пунктчаларда күрсәтелгән вакытлардан артмау шарты белән. Авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан әлеге пунктның «а» – «б» пунктчалары нигезендә тотылган чыгымнарны яңадан финанслауга (каплауга) алынган, түләү чыганаклары акционерлык, облигация заемнары булган һәм 2015 елның 1 гыйнварыннан соң башкарылган кредитлар (заемнар) буенча, кредитлардан (заемнардан) файдалануның гомуми вакыты әлеге пунктчаларда күрсәтелгән вакытлардан артмау шарты белән.»;

8 нче пунктта:

«а» пунктчасында «мөгезле эре терлек итен һәм сөт җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) һәм агросәнәгать комплексына караган теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге оешмалар тарафыннан алынган әлеге кредитлар (заемнар) буенча» сүзләрен «итле һәм сөтле терлекчелекне үстерүгә, шул исәптән авыл хуҗалыгы техникасын сатып алуга алынган кредитлар (заемнар) буенча (итле һәм сөтле терлекчелеккә булышлык күрсәтүгә алынган кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча 2008 елның 1 гыйнварыннан 2012 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне дә кертеп) 10 елга кадәр һәм 15 елга кадәр вакытка төзелгән кредит шартнамәләре буенча)» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «мөгезле эре терлек итен һәм сөт җитештерү белән шөгыльләнүче» сүзләрен «сөтле һәм итле терлекчелекне үстерүгә алынган кредитлар (заемнар) буенча» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле «б$^1$» пунктчасын өстәргә:

«б$^1$) әлеге Тәртипнең 4 нче пунктындагы «в$^1$» пунктчасы белән каралган кредитлар (заемнар) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкы яңадан финанслау

ставкасының (исәп ставкасының) 1 проценты күләмендә, күпләп сату-бүлү үзәкләрен үстерүгә алынган кредитлар (заемнар) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкы яңадан финанслау ставкасының (исәп ставкасының) өчтән бере күләмендә, ләкин Россия Федерациясе Үзәк банкы яңадан финанслау ставкасының (исәп ставкасының) 20 процентыннан ким түгел»;

12 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 4 нче пунктындагы «а» – «в[1]» пунктчалары белән күздә тотылган кредитлар (заемнар) буенча бу пунктта каралган документлар кредит шартнамәсен төзегән көннән соң 6 ай эчендә заемга алучы тарафыннан вәкаләтле органга кертелә.»;

әлеге карар белән расланган 2015 елда хуҗалык итүнең кече формалары алган озак вакытлы һәм кыска вакытлы кредитлар буенча процент ставкасын түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

10 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге пунктта күрсәтелгән документлар 2016 елның 1 гыйнварыннан кредит шартнамәсенең гамәлдә булу вакыты чыкканнан соң, 6 айдан да соңга калмыйча, заемга алучы тарафыннан кертелергә тиеш.»;

12 нче пунктта:

икенче абзацта «20 көн эчендә» сүзләрен «эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«заемга алучының әлеге Тәртипнең 10 нчы пункты белән күздә тотылган документларны кредит шартнамәсенең гамәлдә булу вакыты чыкканнан соң 6 ай үткәч кертүе.»;

14 нче пунктта «биш көн эчендә» сүзләрен «эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда кыска вакытлы кредитлар (заемнар) буенча процент ставкасын түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктта:

«б» пунктчасының беренче абзацында «1 елга кадәр вакытка» сүзләреннән соң «2015 елның 31 июленә кадәр (31 июльне дә кертеп)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасын өстәргә:

«в) 2015 елның 1 августыннан 1 елга кадәр вакытка төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш) һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә үсемлекчелек ярдәмче тармагын үстерү максатларына;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш) һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә терлекчелек ярдәмче тармагын үстерү максатларына;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып

баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш), крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә сөтле терлекчелек ярдәмче тармагын үстерү максатларына;

авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар, кулланучылар кооперациясе оешмалары тарафыннан – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә, беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүе өчен үсемлекчелек продукциясе авыл хуҗалыгы чималын сатып алуга һәм авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүе өчен терлекчелек продукциясе, үсемлекчелек продукциясе (яшелчәчелек, бакчачылык, виноградчылык, бәрәңгечелек, бакчачылык һәм ябык грунт продукциясе) авыл хуҗалыгы чималын сатып алуга;

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш) һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә үсемлекчелектә селекция-орлыкчылык үзәкләрен һәм терлекчелектә селекция-генетика үзәкләрен үстерү максатларына.»;

9 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасын өстәргә:

«в) әлеге Тәртипнең 4 нче пунктындагы «в» пунктчасы белән күздә тотылган кредитлар (заемнар) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкы яңадан финанслау ставкасының (исәп ставкасының) өчтән бере чикләрендә, сөтле һәм (яки) итле терлекчелекне үстерүгә, мөгезле эре терлек итен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүен кертеп, шулай ук үсемлекчелектә селекция-орлыкчылык үзәкләрен һәм терлекчелектә селекция-генетика үзәкләрен үстерүгә алынган әлеге кредитлар (заемнар буенча) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкы яңадан финанслау ставкасыннан (исәп ставкасынннан) тыш 3 процент пункты чикләрендә, ләкин заемга алучыга чыгымнарының бер өлешен каплауга бирелә торган акчаның 5 процентыннан ким түгел.»;

әлеге карар белән расланган 2015 елда авыл хуҗалыгы җитештерүен техник һәм технологик модернизацияләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибендә:

5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле «л» пунктчасын өстәргә:

«л) авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә финанс аренда (лизинг) шартнамәләре буенча сатып алынган авыл хуҗалыгы техникасы, җиһазлар, махсус яки йөк автомобиль транспорты өчен, өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча – беренчел кертемнең һәм (яки) агымдагы лизинг түләүләренең 40 проценты күләмендә.»;

$12^1$ нче пунктта:

беренче абзацта «5 нче пунктның «к» пунктчасында» сүзләрен «5 нче пунктның «к» – «л» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «төзелгән финанс аренда (лизинг) шартнамәсе күчермәләре»

сүзләренә кадәр «2006 елдан да иртәрәк булмаган вакытта» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «2015 ел өчен агымдагы лизинг түләүләрен түләү турында банк өземтәләре белән түләү йөкләмәләре» сүзләрен «2015 ел өчен беренчел кертемнәрне һәм (яки) агымдагы лизинг түләүләрен түләү турында банк өземтәләре белән түләү йөкләмәләре» сүзләренә алмаштырырга;

18 нче пунктның икенче абзацындагы «з» – «к» пунктчаларын шул ук эзлеклелектә «з» – «л» пунктчалары дип санарга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтада:

«Өстәмә лимит (Төбәк азык-төлек фондын булдыру максатларында тапшырылган ашлык өчен)» юлында «412 606» саннарын «57 392,0» саннарына алмаштырырга;

44 нче пунктта «40 000» саннарын «30 000» саннарына алмаштырырга;

48 нче пунктта «50 000» саннарын «40 000» саннарына алмаштырырга;

51 нче пунктта «20 000» саннарын «10 000» саннарына алмаштырырга;

52 нче пунктта «25 000» саннарын «15 000» саннарына алмаштырырга;

55 нче пунктта «50 000» саннарын «40 000» саннарына алмаштырырга;

«Барлыгы» пунктында «2 240 894» саннарын «1 835 680» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда ветеринария-санитария савыктыруы чараларын финанслау тәртибендә:

3 нче пунктта «инструментлар һәм лаборатория җиһазы» сүзләреннән соң «, эш автотранспорты» сүзләрен өстәргә;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтада:

| «Т/с | Муниципаль район, дәүләт учреждениесе исеме | Финанслау лимиты, мең сум» |
|---|---|---|

юлын

| «Т/с | Муниципаль район, дәүләт учреждениесе исеме, финанслау юнәлеше | Финанслау лимиты, мең сум» |
|---|---|---|

юлына алмаштырырга;

таблицага түбәндәге эчтәлекле 46 нчы пункт өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «46 | Эш автотранспорты сатып алуга | 18 000,0»; |

«Барлыгы» юлында «45 000,0» саннарын «63 000,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

2015 елда шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга мөгезле эре терлектән булган таналарны сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирүгә финанслау лимитларын Татарстан Республикасы муниципаль районнары буенча бүлү

| Т/с | Муниципаль район исеме | Субсидияләр лимиты, мең сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Әгерҗе | 727,9 |
| 2 | Азнакай | 996,6 |
| 3 | Аксубай | 1 388,6 |
| 4 | Актаныш | 1 679,7 |
| 5 | Алексеевск | 839,9 |
| 6 | Әлки | 895,8 |
| 7 | Әлмәт | 649,5 |
| 8 | Апас | 761,5 |
| 9 | Арча | 1 937,3 |
| 10 | Әтнә | 907 |
| 11 | Баулы | 716,7 |
| 12 | Балтач | 1 735,7 |
| 13 | Бөгелмә | 414,3 |
| 14 | Буа | 1 086,2 |
| 15 | Югары Ослан | 156,8 |
| 16 | Биектау | 761,5 |
| 17 | Чүпрәле | 1 713,3 |
| 18 | Алабуга | 257,6 |
| 19 | Зәй | 604,7 |
| 20 | Зеленодольск | 604,7 |
| 21 | Кайбыч | 537,5 |
| 22 | Кама Тамагы | 593,5 |
| 23 | Кукмара | 1 623,7 |
| 24 | Лаеш | 302,3 |
| 25 | Лениногорск | 492,7 |
| 26 | Мамадыш | 1 276,6 |
| 27 | Менделеевск | 257,6 |
| 28 | Минзәлә | 884,6 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 29 | Мөслим | 1 220,6 |
| 30 | Түбән Кама | 582,3 |
| 31 | Яңа Чишмә | 671,9 |
| 32 | Нурлат | 1 444,6 |
| 33 | Питрәч | 447,9 |
| 34 | Балык Бистәсе | 940,6 |
| 35 | Саба | 895,8 |
| 36 | Сарман | 1 063,8 |
| 37 | Спас | 963 |
| 38 | Тәтеш | 671,9 |
| 39 | Тукай | 582,3 |
| 40 | Теләче | 638,3 |
| 41 | Чирмешән | 638,3 |
| 42 | Чистай | 1 231,8 |
| 43 | Ютазы | 530,1 |
| Барлыгы | | 37 327,0»; |

әлеге карар белән расланган 2015 елда Татарстан Республикасы территориясенә дуңгызларның африка чумасын кертүне һәм таратуны кисәтү чараларын финанслау тәртибенең 3 нче пунктында «лаборатория җиһазы, махсус автотранспорт» сүзләреннән соң «, саклау киеме» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\901.doc